РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» июля 2022 г. г. Альметьевск № 1490

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районының Физик культура,
спорт һәм туризм идарәсенә гамәлгә
куючының аерым функцияләрен һәм
вәкаләтләрен тапшыру турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Физик культура, спорт һәм туризм идарәсенә (алга таба - Идарә) ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләргә карата функция һәм гамәлгә куючының вәкаләтләрен түбәндәге өлештә бирергә:

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы һәм гамәлгә куючы белән килештереп, барлык дәрәҗәдәге бюджетлар исәбеннән җирле бюджеттан субсидияләр рәвешендә кергән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга акчалар белән эш итү;

муниципаль биремне төзү һәм раслау, аны финанс белән тәэмин итү, муниципаль биремнең үтәлешен тикшереп тору, муниципаль мөлкәткә ия булуның, аннан файдалануның һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәү, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә мөлкәтнең билгеләнешен һәм сакланышын тикшереп торуны гамәлгә ашырырга, оператив идарә итү хокукында муниципаль учреждениеләргә беркетелгән мөлкәтне билгеләү буенча булмаган артык мөлкәтне тартып алу буенча тәкъдимнәр бирергә;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен кабул итү һәм эштән азат итү, аларга дисциплинар җәза бирү һәм кызыксындыру чаралары бирү, шул исәптән барлык төрдәге отпускларны бирү, хезмәт шартнамәләре (контрактлары) төзү;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә беркетелгән муниципаль күчемле мөлкәтне (транспорт чараларыннан тыш) яңадан бүлү, баланс бәясе 100 000 сумга кадәр (мең сум) һәм күчемле мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын раслау буенча карарлар кабул итү.

2. Идарәгә буйсынучы учреждениеләрнең исемлеген расларга (1нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында PRAVO.TATARSTAN.RU урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 14 апрелендә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«18» шагә 2022 ел №1490
карары белән расланган
1 нче кушымта

Идарәгә буйсынучы учреждениеләрнең исемлеге

Табл. №1

| №№ п/п | Учреждение исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Өстәл теннисы буенча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе (ТР Әлмәт муниципаль районының «Өстәл теннисы буенча СМ» МБУ) |
| 2 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе («Юность «спорт мәктәбе» МБУ) |
| 3 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Шахмат буенча спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе (ТР Әлмәт муниципаль районының «Шахмат буенча мәктәп» МБУ) |
| 4 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Олимпия резервының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе (ТР Әлмәт муниципаль районының ОРСМ» МБУ) |
| 5 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Девон «спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе (Әлмәт муниципаль районының «Девон» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе) |
| 6 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Теннис спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе (ТР Әлмәт муниципаль районының «Теннис спорт мәктәбе» МБУ) |
| 7 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Ат спорты мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе (ТР ӘМР «Ат спорты мәктәбе» МАУ) |
| 8 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Футбол буенча спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе («Футбол буенча СМ» МАУ) |
| 9 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Мирас» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном учреждениесе (ТР ӘМР «Мирас» ССК» МАУ) |
| 10 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Габдрахман авылы «Спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном учреждениесе (ТР ӘМР Абдрахман авылы «ССК» МАУ) |
| 11 | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесе («ТР ЩМР ФКСТИ ҮБ» МБУ) |
| 12 | «Залаев Сирин Шамил улы исемендәге спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном учреждениесе («Залаев Сирин Шамил улы исемендәге ССК» МАУ) |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль
мәсьәләләр буенча урынбасары
вазыйфаларын башкаручи Д.В. Косарев